**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7794**
**01.12.2021**

Башкарма комитетның 2018 елның 1 ноябрендәге 6510 номерлы карары белән расланган «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, шәһәр Уставының 53 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 1 ноябрендәге 6510 номерлы карары (Башкарма комитетның 2019 елның 8 ноябрендәге 5758 номерлы, 2019 елның 27 ноябрендәге 6143 номерлы, 2021 елның 12 мартындагы 1709 номерлы, 2021 елның 3 ноябрендәге 7224 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасына, 6 бүлектәге 4 бурычның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Туган телдә (татар, рус) иң яхшы дәресләр, чаралар үткәрү буенча җыентык бастырып чыгару | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2019-2021 еллар | Данәләр саны | 100 | 100 | 100 | 100 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 30,0 | 50,0 | Балалар һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов